Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы

КАРАР

31 июль, 2024 ел № 24

***Ятмас-Дусай авыл җирлеге җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында***

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Уставы нигезендә Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Кукмара муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Ятмас-Дусай авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә:

җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлеген, гомуми булмаган файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлеген раслау өлешендә юл эшчәнлеге.

2. Кукмара муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Ятмас-Дусай авыл җирлеге Башкарма комитетына:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Ятмас-Дусай авыл җирлеге бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү хакында Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә халыкка җиткерелгән көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны икътисадый һәм бюджет-финанс

проблемалары буенча Кукмара муниципаль районының Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы даими комиссиясенә йөкләргә.

Ятмас-Дусай җирлеге
башлыгы урынбасары Н.Г.Галиев